| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 нчы сентябрь Олы Подберезье авылы № 11

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Олы Подберезье авыл җирлегендә җирле**
**референдум үткәрү инициативасы**
**турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Олы Подберезье авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны, җирле референдум мәсьәләләрен формалаштырып, түбәндәгечә тәкъдим итәргә:

"Сез 2020 елда 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә хокуклы Олы Подберезье авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү кертүгә килешәсезме?

*а)* җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, күперләрне ремонтлау;

*б)* җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлек торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын тоту;

в) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

-материаллар сатып алган зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмати стендларда һәм Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://bpberez-kaybici.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Советына җибәрергә.

4. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Татарстан Республикасы Кайбыч**
**муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Ф.А.Чекмарев**